| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУСЛЮМОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕТАБЫНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ТҮБӘН ТАБЫН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
|---|---|---|

*Юрид.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10*
*Факт.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 19б*
Тел./факс: 8-85556-32874/Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629003865, КПП 162901001, ОГРН 1061687001166, ОКТМО 92642450


**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е № 03-5**

***Югары Табын авылы*** ***“20” нче март, 2019 нчы ел***

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Түбән Табын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 7 статьясы нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм яклау максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Хөкүмәте Документлар ТР Хөкүмәте карарлары ТР Хөкүмәте карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елгы язгы ташу чорында Түбән Табын авыл җирлеге халкын һәм территорияләрен яклау чаралары планын 1 нче кушымта итеп расларга.

2.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге икътисад объектларының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияне тәкъдим итәргә:

- КЧСПБ утырышларында, авыл жирлегенең кризиска каршы комиссиясе утырышларында язгы ташу суларын авариясез уздырып җибәрүне тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;

– язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә реакция ясау һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын төгәлләштерүне оештырырга. Көч һәм чаралар турында мәгълүматларны җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен контрольдә тотуны оештыру, язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;

- язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән халыкны һәм территорияләрне саклау буенча чаралар үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

3. Мөслим муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиягә «ташу» планын тормышка ашыру турында мәгълүматларны 23.03.2019 нчы елга кадәр тапшырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам

***Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы*** ***С. М. Гыйльманова***

*Түбән Табын авыл җирлеге*
*Башкарма комитет җитәкчесе*
*вазыйфаларын башкаручының*
*20.03.2019 нчы ел № 03-5 карарына*
*1 нче кушымта*

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары буенча план**

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | 2019 елгы язгы ташуга әзерлек мәсьәләсе буенча утырыш үткәрү. | 20.03. | Башкарма комитет |
| 2. | Авыл җирлеге территориясендә язгы ташу күренешләре белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча оператив планны корректировкалау, аны үтәү өчен җәлеп ителә торган көч һәм чаралар оештыру. | 21.03. | Башкарма комитет |
| 3. | Юл торышын, юлсызлык вакытында керү юлларын контрольдә тотуны оештыру | язгы ташу чоры | Башкарма комитет |
| 4. | Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә урнашкан оешма, учреждение җитәкчеләре белән гадәттән тыш хәл килеп чыкканда кагыйдәләр турында әңгәмә үткәрергә | 21.03. | Башкарма комитет |
| 5. | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга җыеннар барышында гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзләрен дөрес тоту турында әңгәмәләр уздыру, кагыйдәләрне халыкка җиткерү, мәгълүмати стендлар урнаштыру | язгы ташу чорына кадәр | Башкарма комитет, мәктәп директорлары, клуб директорлары, ФАПлар |
| 6. | Су басу куркынычы булган зонага керә торган торак биналардан һәм корылмалардан җыелган суларны алдан җибәрү эшләрен оештыру | язгы ташу чоры | Башкарма комитет, шәхси йорт хуҗалары, оешма җитәкчеләре |
| 7. | Язгы ташу чорында зыян күргән кешеләргә медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләрен үткәрү. | язгы ташу чоры | Башкарма комитет, Үзәк больница, ФАПлар |